**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы**
**Туктар-Урдаласы авыл җирлегенең**
**Туктар-Урдаласы торак пункты гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

2023 елның 18 ноябре № 1

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Туктар-Урдаласы авыл җирлегенең Туктар-Урдаласы торак пункты гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 18 ноябрендә «Сез 2024 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Туктар-Урдаласы авыл җирлеге Туктар-Урдаласы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, ялгыз картлар һәм аз керемле гражданнар, түләүле нигездә белем алучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 500(биш йөз) сум күләмендә билгеләү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:

торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

Туктар - Урдаласы торак пунктында Вахитов урамы, Октябрь урамы буенча юлларны вак таш белән каплау;

Туктар - Урдаласы торак пунктында, Совет, Вахитов, Тукай, Октябрь, Куйбышев урамнарында юлларны кардан чистарту.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 316 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 162.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «РИЗА» позициясе өчен гражданнар сходында катнашучы 53 кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Туктар-Урдаласы авыл җирлегенең Туктар-Урдаласы торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Туктар-Урдаласы авыл җирлеге составына керүче Туктар-Урдаласы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дерес дип танырга.

2. «Сез 2024 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Туктар-Урдаласы авыл җирлеге Туктар-Урдаласы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, ялгыз картлар һәм аз керемле гражданнар, түләүле нигездә белем алучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 500(биш йөз) сум күләмендә билгеләү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:

торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

Туктар - Урдаласы торак пунктында Вахитов урамы, Октябрь урамы буенча юлларны вак таш белән каплау;

Туктар - Урдаласы торак пунктында, Совет, Вахитов, Тукай, Октябрь, Куйбышев урамнарында юлларны кардан чистарту.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Туктар-Урдаласы авылы, Совет ур., 98 адресы буенча урнашкан административ бинада, Совет ур., 103 йорт, Туктар-Урдаласы авылы, Тельман ур., 31 йорт адресы буенча КФҮ бинасында урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәнннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы
Туктар-Урдаласы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге
башлыгы Г.Ә.Әхмәтова